# 2012 елга үз-үзеңне тикшерү нәтиҗәләре

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының “Кукмара ш.т.п.дүртенче номерлы «Ләйсән» балаларны һәрьяктан тәрбияләп үстерү буенча балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе 1961 елда ачылган, 1996 елда яңа бинага күченеп, бүгенге көндә дә шушы бинада эшли. Планетарная урамы 2 йортта урнашкан. 2012-2013 уку елында 6 төркем эшләде. 110 урынга исәпләнеп төзелгән балалар бакчасында 146 бала тәрбияләнде, 82 бала рус телен өйрәнделәр.

2012 елның 1 сентябреннән яңа УМК, “Балалар бакчасының төп белем бирү программасы” нигезендә эш алып барылды.

Балалар бакчасы педагогик кадрлар белән тулысынча тәэмин ителгән.

**15 педагогик кадрның**:

- 65% югары;
- 35% махсус урта белемле;
- 3 педагог югары;
- 8 педагог I квалификацион категориягә ия;
- 4 педагог категориясез.

**Белгечләр**:

- рус теленә өйрәтүче тәрбияче;
- музыка җитәкчесе;
- физик тәрбия бирү инструкторы;
- укытучы - логопед.

Район психологы балаларга коррекцион ярдәм күрсәтә.

2012- 2013 уку елында Загидуллина И.Р. беренче квалификацион категориягә, Билалова Г.Ш., Нигматуллина З.М. югары категориягә лаек булдылар.

2012 - 2013 уку елында Салимгараева Н.Ф., Якубова Г.Р., Газизова И.Я. Бөгелмә икъдисат һәм идарә институты оештырган белем күтәрү курсларында укыдылар, Якубова Г.Р., Ашрапова Г.Р., Газизова И.Я. Бөгелмә икъдисат һәм идарә институты оештырган өстәмә белем бирү курсларында укып балалар бакчасында методист дипломы алдылар.

Балалар бакчасы яны эстетик зәвык белән бизәлгән. Уен мәйданчыклары махсус корылмалар белән эшләнгән. Җәйге айларда уен мәйданчыкларында балалар өчен тәгәрәмәчләрдән машина, автобус, мотоцикл кебек эшләнмәләр

эшләнде, уен мәйданчыкларындагы корылмалар буяп яңартылды. Верандага идән түшәлде, беренче кечкенәләр, ике икенче кечкенәләр төркемнәрендә бойлер куелып савыт-саба юю һәм юыну бүлмәсенә җылы су сузылды. Күп төрле һәм чәчәк ату циклын исәпкә алып бакча чәчәкләре, зәңгәр чыршылар утыртылды. Бу балаларда эстетик зәвык тәрбияләүгә этәргеч бирә, балаларның танып-белүчәнлекләрен үстерүгә этәргеч булып тора.

**Балалар бакчасы 2012-2013 уку елыннан ФДТ туры китереп "Балалар бакчасының төп белем бирү программасы" нигезендә эш алып барды.** Программа:

- "Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы" М.А.Васильева, В.В.Гербова, Т.С.Комарова редакциясендә, "Мозаика-Синтез", 2005";
- "Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы" (Милли регионал компонент) К.В. Закирова, Р.А.Борһанова, Казан, "Хәтер" нәшрияты, 2010 ел;
- «Төбәкнең мәктәпкәчә белеем бирү программасына» Шаехова Р.К., Казан, РИЦ, 2012;
- "Основа безопасности жизнедеятельности детей старшего возраста» Н.Н.Авдеева, О.А.Князева, Р.Б.Стеркина;
- "Татар халкының мәдәнияте белән таныштыру" Р.Г. Борһанова;
- "Гаиләдә балалар бакчаларында әдәплелек тәрбияләү" К.В.Закирова;
- "Программа экологического воспитания для детей дошкольного возраста» Н.С. Калегина;
- "Я, ты, мы" Р. Стеркина, О. Князева;
- "Аппликация в детском саду" Д.Н.Колдина;
- "Лепка в детском саду" Д.Н.Колдина;
- "Рисование в детском саду" Д.Н.Колдина;
- «Экологическое воспитание детей дошкольного возраста» Т.А.Носкова;
- «Ладушки» И.Д.Каплунова, И.Д. Новоскольцева;
- «Занятия с палочками Кюизенера» Новикова Л.Р. нигезләнеп төзелгән.

Алынган программалар нигезендә җитди эш оештырылды. Программа бурычларын үтәүгә һәр педагог мөмкин кадәр иҗади якын килеп эшләде. Уку елы барышында О.А. Сафонованың «Бала эшчәнлегенә бәя һәм экспресс анализ» методик кулланмага нигезләнеп балалар эшчәнлегенә анализ ясалды. Диагностика нәтиҗәләренә таянып педагогик эшчәнлек оештырылды.

**Диагностика күрсәткечләренең нәтиҗәләре**:

| Эшчәнлек төрләре | Сөйләм үстерү | | | Уен эшчәнлеге | | | Конструкция-ләү | | | Сәнгать эшчәнлеге | | | Хәрәкәт эшчәнлеге | | | Музыка | | | Хезмәт эшчәнлеге | | | Элементар математик күзаллаулар формалаштыру | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Уку еллары | 2010-2011 | 2011-2012 | 2012-2013 | 2010-2011 | 2011-2012 | 2012-2013 | 2010-2011 | 2011-2012 | 2012-2013 | 2010-2011 | 2011-2012 | 2012-2013 | 2010-2011 | 2011-2012 | 2012-2013 | 2010-2011 | 2011-2012 | 2012-2013 | 2010-2011 | 2011-2012 | 2012-2013 | 2010-2011 | 2011-2012 | 2012-2013 |
| Оптималь балл | 22 | 7 | 15 | 18 | 10 | 14 | 10 | 7 | 11 | 11 | 7 | 8 | 2 | - | 4 | - | | - | 18 | 9 | 5 | 3 | 1 | 3 |
| Югары балл | 43 | 40 | 42 | 51 | 41 | 45 | 53 | 30 | 41 | 51 | 41 | 42 | 53 | 37 | 38 | 81 | 42 | 86 | 46 | 52 | 53 | 17 | 27 | 48 |
| Уртача балл | 33 | 48 | 43 | 29 | 47 | 41 | 34 | 61 | 48 | 37 | 45 | 50 | 41 | 57 | 58 | 19 | 54 | 14 | 36 | 39 | 42 | 57 | 61 | 49 |
| Түбән балл | 2 | 8 | - | 2 | 2 | - | 3 | 2 | - | 1 | 7 | - | 4 | 6 | - | - | 4 | - | - | - | - | 23 | 11 | - |

**2012-2013 уку елында:**

- зурлар төркемендә элементар математик күзаллаулар формалаштыру;
- уртанчылар төркемендә элементар математик күзаллаулар формалашты, сөйләм үстерү,
- икенче кечкенәләр төркемендә элементар математик күзаллаулар формалаштыру, сөйләм үстерү, хезмәт эшчәнлекләрен оештыру сыйфатын күтәрү максат куелды.

**2008 уку елыннан эшнең төп юнәлеше итеп танып белү эшчәнлеген һәм сөйләм телен үстерү алынды.**

Белем бирүнең сыйфатын үстерү – шулай ук, педагогның профессиональ әзерлегенә, профессиональ – шәхси сыйфатына бәйле. Барлык педагоглар даими рәвештә үзләренең белемнәрен күтәрәләр. Тәрбиячеләрнең профессиональ үсешен тәэмин итү өстендә системалы, максатчан эш оештырылды. Алып барган эшнең нәтиҗәсе буларак –

тәрбиячеләр Газизова И.Я, Хурамшина Г.Г.  Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге исеменнән мактау грамотасы белән бүләкләнделәр.

Тәрбиячеләр район методик берләшмә утырышларында, конференцияләрдә  актив катнашалар. Ноябрь  аенда район тәрбиячеләре өчен “Балаларга рус теле өйрәтүдә яңа укыту-методик комплектлары куллану” темасына үткәрелгән семинар-практикумда Салимгараева Н.Ф. “Балаларга рус теле өйрәтүдә яңа укыту-методик комплектлары куллану”, Мостафина Г.Х. “Балаларны рус теленә өйрәтүдә төркем тәрбиячесе  һәм рус теленә өйрәтүче тәрбиячене ң бердәм эшләве темасына чыгыш-презентацияләр,  рус теленә өйрәтүче тәрбияче Салимгараева Н.Ф. зурлар төркеме балалары белән “Мин яшәгән өй” дигән бердәм белем бирү эшчәнлеге күрсәттеләр.

Декабрь аенда район музыка җитәкчеләре өчен “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның үсешендә музыкаль-ритмик хәрәкәтләрнең роле” дигән семинар-презентация уздырдык. Бу семинарда музыка җитәкчесе Загидуллина И.Р.”Сәламәтлек шәһәре һәм аның халкы” темасына музыка эшчәнлеге күрсәтте,  “Музыка эшчәнлегендә сәламәтләндерү эше”, укытучы-логопед Якубова Г.Р. “Музыка җитәкчесе һәм укытучы-логопедның коррекция эшендә бердәм эшчәнлеге” дигән темага чыгыш-презентация ясады.

Февраль аенда А.М.Булатов исемндәге күппрофилле лицей базасында узган мәгариф хезмәткәрләренең  Ризаэтдин Фахреддин исемендәге X республикакүләм педагогик укуларында катнаштык. Бакча тәрбиячесе Габделхаева Г.И. кызы “Икмәк- тормыш нигезе” дип аталган мастер- класс күрсәтте. Мастер –класс педагогик укуларда катнашкан барлык укытучыларда уңай тәэсир калдырды.  Башкарылган эшнең нәтиҗәсе буларак Кукмара муниципаль районының мәгълүмәти  методик үзәге исеменнән   рәхмәт хатлары белән бүләкләндек.

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә: методик бүлмә, музыка залы, юл йөрү кагыйдәләрен, логопед, рус телен өйрәнү өчен бүлмәләр җиһазландырылган. Бу уку елында ДАИ балалар бакчасына уенчыклар, эшли торган светофор, стенд һәм фотоаппарат бүләк итте.. Балалар бакчасы эчендәге барлык стендларның эчтәлеге яңартылды.

**2012-2013 уку елында бердәм коллектив алынган бурычларны тормышка ашыру өстендә җитди эш алып барды**:

I. Хезмәт тәрбиясе аша балаларның танып белү эшчәнлеген үстерү

II. Хәрәкәт активлыгын үстерү аша балаларның сәламәтлекләрен ныгыту

III. Яңа укыту-методик комплектларын кулланып балаларның сөйләм телен үстерү  буенча  эшне камилләштерү.

Алынган бурычларны тормышка ашыру максатыннан иң элек тәрбиячеләр белән эш төрле формаларда оештырылды. “Эшчәнлек  барышында ИКТ кулану», «Көн дәвамында музыкаль ритмик уеннар куллану”, “Элементар

математик шөгыльләрне формалаштыру шөгыльләрендә Кюзинер таякчыклары куллану", "Яңа укыту методик коплектлары буенча балаларны грамотага өйрәтү", "Интернет сайтларга методик материал куярга өйрәнү", "Федераль дәүләт таләпләре буенча эшлибез" исемләнгән семинар-практикумнар файдалы һәм эчтәлекле булды. Тәрбиячеләр өчен өлкән тәрбияче Нигматуллина З.М. оештырган "Яңа укыту методик комплектларының эш дәфтәрләре буенча кичке вакытта эш алып бару", "ФДТ буенча көндәлек режимны планнаштыру", "ФДТ буенча тәрбия һәм белем бирү эшен планнаштыруда заманча таләпләр", Хурамшина Г.Г. "Интернет сайтларда балаларның кул эшләрен ничек урнаштырырга", Сабирова М.М." Балалар бакчасында экологик экскурсияләр оештыру», Якубова Г.Р. «Балаларның аваз әйтүләрен төзәтүдә уеннар", Загдуллина И.Р. "Ритмик уеннарны көндәлек тормышта куллану" дигән темага консультацияләр педагоглар өчен кызыклы һәм практик яктан файдалы булды.

Барлык тәрбиячеләр актив катнашында педагогик киңәшмәләр үткәрелде. Тәрбиячеләрнең үз тәҗрибәләре белән уртаклашу чыгышлары эчтәлекле һәм файдалы оештырылды. Педагогик киңәшмәнең карарлары төгәл үтәлде.

Үзара тәҗрибә уртаклашу максатыннан ачык дәресләр үткәрелде. Төркем тәрбиячеләре әзерләгән "Иң кече яшьтәге балаларны гади хезмәт күнекмәләре белән таныштыру","Балаларны бакчада булган һөнәрләр белән таныштыру (интегральләштерелгән шөгыльләр)", "Уенчыклар ярдәмендә хәрәкәтле уеннар оештыру", "Балаларның хәрәкәт активлыгын үстерүдә хәрәкәтле уеннар куллану", "Иң кече яшьтәге балалар өчен коммуникатив уеннар", "Сөйләм үстерү шөгыльләрендә яңа методик комплектлар куллану" дигән тема астында оештырылган ачык бердәм белем бирү эшчәнлеге барышында тәрбиячеләр яңа эш алымнарын һәм методларын кулллануны өйрәнделәр. Бердәм белем бирү эшчәнлеге үткәргән һәр тәрбияче үз эшенә җаваплы карап, эшчәнлек үткәрүгә иҗади якын килгән. Бигрәк тә мәктпкә әзерлек төркемендә Гыйләҗева Н.С. үткәргән "Пешекче һөнәре" темасына үткәрелгән эшчәнлекне әйтеп үтәсе килә. Эшчәнлек барышында балалар пешекче һөнәре белән танышып кына калмыйча, үзләре дә нәни пешекчеләргә өйләнеделәр. Бу балаларда хезмәт тәрбиясе бирүдә зур этәргеч булып тора. "Төркемнәрдә хезмәт тәрбиясе бирү" тематик тикшерү нәтиҗәсендә бу эшнең яхшы дәрәҗәдә оештырылганлыгы билгеләнде.

Уку елы дәвамында барлык тәрбиячеләр яңа методик әдәбият, газета һәм журналлар белән даими танышып тордылар. "Өлкән тәрбияче", "Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тәрбиячесе" дип исемләнгән яңа журналларның эчтәлеге педагогларга ошады. Даими рәвештә педагоглар яңа методик әсбаплар эчтәлеге белән танышып торалар.

Педагогларның алдынгы эш тәҗрибәсен өйрәнү, берләштерү һәм тарату максатыннан Загидуллина И.Р.. белән эш оештырылды. "Балаларны тәрбияләүдә музыкаль-ритмик хәрәкәтләрнең роле"темасы астында педагогның эш тәҗрибәсе таратылды.

Бүгенге көндә балаларны сәламәтләндерү, аларның физик үсеше өчен кирәкле шартлар булдыру гаять әһәмиятле мәсьәләгә әверелде. Барлык төркемнәрнең көндәлек эш планнарында, ике атнага бер тапкыр сәламәтләндерү эше перспектив план нигезендә планлаштырылып оештырылды.

2012-2013 уку елында балаларның сәламәтлеген саклау аша физик үсешен тәэмин итү өстендә эш алып барылды. Уку елы барышында физкультура дәресләренең тыгызлыгы, сәламәтләндерү эшенең торышы тикшерелде. Дәресләрнең тыгызлыгы 75 %, баланың дәрестә хәрәкәттә булу вакыты 71 % булу билгеләнде. Бу юнәлештә эшләргә кирәклеге исбатланды. Бу эшне дәвам итү максаты куелды.

Күңел ачу планы нигезендә планнаштырылган спорт бәйрәмнәре төгәл үтәлде. Алар арасында “Юни белән бергәләп”, “23 февраль – Ватанны саклаучылар көне”, “Сәламәтлек –зур байлык” бәйрәм кичәләре, бакчада “Сәламәтлек көне” үткәрү игътибарга лаек. “Зилант” спорт мәктәбе һәм “Олимп” боз сарае белән тыгыз элемтәдә эш оештырылды. “Зилант” спорт мәктәбе белән берлектә ата-аналар өчен оештырылган “Юни белән бергәләп” спорт бәйрәменә тукталып үтәсе килә. Әлеге эшләр нәтиҗәсе буенча балаларның авырып калдырган көннәре кимеде, ләкин шулай булса да район күрсәткече дәрәҗәсенә тигезләшер өчен алга таба эш алып барасы бар әле.

| Уку елы | Район буенча | Балалар бакчасы буенча |
|---|---|---|
| 2010 | 3.9 | 4,0 |
| 2011 | 3,4 | 3,9 |
| 2012 | 3,2 | 3,8 |

Бакчада тәрбия һәм белем бирү эше татар телендә бару сәбәпле рус теленә нык игътибар бирелә. Төп бурычлардан берсе - балаларга мәктәпкә бару өчен башлангыч әзерлек бирү. Рус теле тәрбиячесе Сәлимгәрәева Н.Ф. балаларга рус телен өйрәтү буенча эш алып барды. 2012 елның 1 мартыннан балалар бакчасы экспериментал мәйдан буларак Гафарова С.М. җитәкләгән авторларның «Обучение русскому языку”(“ХӘТЕР” нәшрияты, 2011 ел) методик ярдәмлеге буенча уртанчылар төркемендә рус теле шөгыльләре алып барыла башлады.

Укытучы-логопед Якубова Гүзәл Рамил кызы 42 баланың дөрес сөйләм булдыру өстендә эш оештырды. Башлаган эшне ата-аналар белән берлектә тәрбиячеләр: Газизова И.Я., Гыйләҗева Н.С., Мустафина Г.Х., Хурамшина Г.Г. дәвам иттеләр.

Уку елы юл хәрәкәте иминлеге дирекциясе хезмәткәрләре белән берлектә үтте һәм алар безнең эшне югары бәяләделәр. Сабирова М.М, Хурамшина Г. Г. “Юл кагыйдәләрен беләсеңме” бәйрәм кичәсен, Гыйләҗева Н.С., Загидуллина И.Р. “Кызыл калфак мажаралары”театралләштерелгән тамаша оештырдылар. Балаларның белеменә, бәйрәм кичәләрнең эчтәлегенә зур бәя бирелде һәм бүләкләр балаларга тапшырылды. Календарь планнарга атна саен юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү буенча эш планнаштырырга һәм аны аерым дәфтәргә теркәп барырга кирәклеге ачыкланды.

Балаларны үз милләтен, туган туфрагын, нигезен, әти-әнисен, әби- бабаларын, үз нәселен, туган телен яратучылар итеп тәрбияләүгә зур әһәмият бирелә. Балалар бакчасында балаларга патриотик тәрбия бирүгә эш планы төзелде һәм тулысынча үтәлде. 21 февраль- туган тел көне, бөек шагыйребез Г.Тукайның 127 еллыгы бәйрәм ителде. Төбәкне өйрәнү музеена мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән экскурсия кызыклы һәм файдалы оештырылды. Балалар тәрбия һәм яңа белем алып кайттылар. Экскурсоводның сөйләмен дулкынланып тыңладылар. “Җиңү паркы”нда тере чәчәкләр тотып шигырьләр сөйләү, тынычлык минуты балаларның хәтерләрендә калды. Эшләгән эшләрне туплап, патриотик тәрбиягә багышланып ачылган папка эчтәлеген тулыландыру эше даими бара.

Бөек Җиңүнең 68 ел тулу уңаеннан балалар бакчасында “Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый” күңел ачу кичәсе оештырылды. Балалар килгән кунакның сөйләвен тын да алмыйча тыңладылар, ул елларның авырлыгын күз алдына китерделәр.

Күңел ачу планы тулысынча үтәлде. Милли җирле компонентны кулланып “Масленица”, “Роберт Миңнуллин- балалар шагыйре”, “Сабантуй” бәйрәм кичәләре бик отышлы булды. Бәйрәмнәрнең тематикасы проект эшчәнлеге нигезендә оештырылды.

Балалар бакчасы коллективы район мәгариф бүлеге, яшьләр һәм спорт комитеты оештырган бәйгеләрдә даими катнаша:

- Россиядә Космос елына, Татарсанда Г.Тукай елына һәм Картлар көненә багышланган район күргәзмә ярминкәсендә “Юннат – 2012” - I урын;
- 2013-2014 уку елына әзерлек буенча район конкурсының “Иң яхшы бакчасы участогы” бәйгесендә - II урынга лаек булдык.

Педагоглар профессиональ бәйгеләрдә актив катнашалар һәм үзләренең осталыкларын даими күтәрәләр. Загидуллина И.Р. “Ел тәрбиячесе -2013” республика конкурсының район этабында катнашып III урынга лаек булды. Тәрбиячеләрнең дәрес эшкәртмәләре даими рәвештә профессиональ Интернет-сайтларда урнаштырылып барыла. Моннан тыш “Радуга открытий” регионара конкурста катнашып Ибрагимова Р.Р. II дәрәҗә, Билалова Г.Ш.һәм

Габделхаева Г.И., Газизова И.Я III дәрәҗә диплом белән, Хурамшина Г.Г., Мостафина Г.Х., Сабирова М.М .катнашучы сертификаты белән бүләкләнделәр. Бакча мөдире Шаһабиева М.Р. бәйгене оештыручыларның рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

Балаларны тәрбияләү эше гаилә белән бакча арасында бердәмлек булганда гына нәтиҗәле була. Балалар бакчасы коллективы һәрдаим әлеге эшчәнлеккә игътибар бирә. Ата-аналар балалар катнашында үтә торган барлык бәйрәмнәргә чакырыла, барлык кичәләр ата-аналар белән бергәләп үткәрелә. Ата-ана баласының нинди тирәлектә яшәвен, тәрбияләнүен, белем алуын күрә, үзе дә активлылыгын арттыра. Әти-әниләргә педагогик белем бирү эшчәнлеге тиешле дәрәҗәдә оештырылды. Гомуми ата-аналар җыелышларында балалар катнашында "Кызыл калфак маҗаралары", "Язгы урман хикмәтләре" театральләштергән тамаша күрсәтелде. Балалар бакчасы педагоглары әти-әниләрне кызыксындырган сораулар буенча даими консультацияләр уздырып торалар "Хезмәт тәрбиясе нәрсәдән башлана?" , "Баланың сәламәтлеге безнең кулларда 4-5 яшьлек баланың сөйләм телен үстерүдә гаиләнең роле", " Баланы дөрес тукланырга өйрәтү", "Балаң мәктәпкә әзерме?" дигән темаларга консультацияләр әти-әниләрдә зур кызыксыну уятты.

Балалар бакчасында әти-әниләр белән берлектә төрле конкурслар уздырыла. Бу уку елында район буенча "Масленица" карачкысы", "Пожарга каршы көрәш", "Юл йөрү кагыйдәләрен үтә" "Электричество", "С.Михалков әсәрләре" конкурслары,"Без табигат балалары" рәсем интернет-конкурсларында катнашырга тәкъдим ителгән иде. " "Юл йөрү кагыйдәләрен үтә" рәсем конкурсында Хурамшин Тимур рә район буенча икенче урынны алды, шулай ук ДАИ дан Мактау грамотасы һәм китап белән бүләкләнде."Яңарыш" Бөтенрәсәй фонды оештырган "Без табигат балалары" рәсем конкурсында Хурамшин Тимур беренче урын алды. Каримов Алмир ССИТ оештырган халыкара конкурста Татарстан буенча икенче урын, "С. Михалков әсәрләре"конкурсында Галимова Камилә Кукмара районы буенча беренче урын алды.

Балалар бакчасы үз эшчәнлеген мәктәпләр, укытучылар белән тыгыз элемтә оештыра. Күп еллар 1 нче татар гимназиясе, 4 нче, 2007-2008 уку елыннан Манзарас авылы мәктәпләре белән тыгыз элемтәдә тора. Балалар мәктәпләргә экскурсиягә баралар. Үзара ачык дәресләрдә булу, укытучылар белән берлектә педагогик киңәшмәләр үткәрү, балаларга белем һәм тәрбия бирү проблемаларын чишү буенча түгәрәк өстәл, "Очрашу кичәсе" кебек эш формалары оештырыла, әнә шулай мәктәпкәчә тәрбия бирү вакытында – баланың мәктәптә яхшы белем алуына нигез салына. Балаларыбызның мәктәптә уку сыйфаты нәтиҗәләре дә куандыра. Укытучылар тарафыннан 2012-2013 уку елында №4 "Ләйсән" балалар бакчасыннан килгән укучыларның уку сыйфаты89% яхшы булуы билгеләнде.

2012-2013 уку елында 28 бала мәктәпкә укырга керде: беренче татар гимназиясенә -7, №2 -1, №4 - 15, Манзарас авылы мәктәбенә - 5 бала.